ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең уңайлы шартларга хокукларын, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмә белән, җирле мөселман дини оешмасының - үзәкләштерелгән дини оешманың -Татарстан Республикасы Мөселманнары Диния нәзарәтенең Бакча-Сарай бистәсендәге "Миңлегулсем" мәчете мәхәлләсе мөрәҗәгатен карап чыгып.

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Вахитов авыл җирлеге, Бакча-Сарай бистәсе, Яшьләр урамы адресы буенча урнашкан, 2000 кв. м. мәйданлы, кадастр номеры 16:15:030202:433 булган - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә «дини файдалану»га рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ә. Әхмәтшин;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.Д. Сәгъдиева;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше башлыгы Н.В. Пичугина;

- Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Кәримов.

4. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру чорын билгеләргә - 2025 елның 12 ноябреннән 2025 елның 1 декабренә кадәр.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин